Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 5 нче татар гимназиясе

# Тема: *“Кинорежиссер Рамиль Төхвәтуллин кунакханәсендә”*

Казань
2019

Максат: **Милли кинофильмнар сәнгатенең башлангыч чоры белән таныштыру, кинорежиссер Р. Төхвәтуллинның тормыш юлы һәм иҗаты, татар фильмларының алып кергән яңалыгы һәм “Зөләйха” әсәрләрнең бүгенге көндә әһәмиятен билгеләү; фәнни эзләнү эшчәнлеген, иҗади фикерләү сәләтен камилләштерү, милли сәнгатебез белән кызыксыну тәрбияләү.**

# ЭПИГРАФ

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да...

*Габдулла Тукай*

# РЕЖИССЕР
# РАМИЛ ТӨХВӘТУЛЛИН



Режиссер Р.Төхвәтуллин 1966 нчы елның 2 нче октябрендә Татарстанның Аксубай поселыгында дөньяга килә. 1987 нче елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Г. Камал исемендәге Академия театрына эшкә кабул ителә. 1999 нчы елда КДУ татар филология бүлегеен, ә 2008 нче елда шул ук югары уку йортының юридик факультетын тәмамлый. Мактаулы исемнәр белән бүләкләнә: Татарстан Республикасының атказанган артисты (1995 нче ел), Татарстан Республикасының халык артисты (2003 нче ел), 2007 нче елда министрлар кабинеты спорт һәм культура мәсьәләре буенча, 2008-2010 нчы елларда КДУда кино сәнгате кафедрасының җитәкчесе.




KAZAN
FIRST
НОВОСТИ КАК ЕСТЬ

## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «ЗӨЛӘЙХА» ДРАМАСЫ БУЕНЧА РЕЖИССЕР Р. ТӨХВӘТУЛЛИН ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ КИНОФИЛЬМ ТӨШЕРЕЛӘ.

“Зөләйха” әсәренең сценаристлары: Р. Төхвәтуллин һәм Юныс Сафиуллин, режиссер-куючы: Рамил Төхвәтуллин, оператор: Әмил Җәләлетдинов, рәссам: Сергей Скоморохов, композитор: Марат Әхмәтшин. рольләрне башкаручылар: Илсөя Төхвәтуллина, Гафур Каюм, Рамил Төхвәтуллин, Феликс Пантюшин, Сергей Смирнов, Александр Купцов, Шәүкәт Биктимиров. Вакыйгалары Татарстанның төрле төбәкләрендә төшерелә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: бу фильм Берлинда үткәрелгән кинофильмнар фестивалендә призга лаек була.




Р.ТӨХВӘТУЛЛИН "АК КЫРАУ" ФИЛЬМЫНДА, 2012 ЕЛ.

# Зөләйха









Көчләп чукындырылган, моның белән килешмәгәне өчен, тугыз ай монастырьда ябып яткырылган, иреннән, газиз балаларыннан аерып, ирексездән рус мужигына хатын ителгән, ләкин рухы белән татар хатыны булып калган, кяфер ирен үтереп, унсигез ел каторгада интеккән Зөләйханың язмышы ул-дөресендә, татар халкы кичергәннәрең бер тамчысы, бер кисәге. Руслар алдында шулкадәр нинди гаебе булган соң Зөләйханың? “Мине хак диннән чыгарырга теләделәр, көчләп алып, ирем бар өстеннән руска иргә бирделәр. Көчләп чукындырдылар. Көчәп ата-анамнан, бала-чагамнан аердылар. Мин, әлхәмделилла, барысына да чыдадым, барысына да! Мин ислам өчен...зәхмәт чиктем”. Зөләйханың бу сүзләрендә конфликтның тулы эчтәлеге яңгырый.

- "Татарстанда милли кинематографиядә иң үзенчәлекле юнәлешләрдән берсе-Р. Төхвәтуллинның "Рамай" студиясе. Бу уңайдан бу студия ярдәмендә иҗат ителгән " Зөләйха" фильмы татар халкы өчен генә түгел, ә башка милләт өчен дә зур әһәмиткә ия." Диллема", "Зөләйха",фильмнары ;"Шүрәле" мультфильмы - Р. Төхвәтуллинның зур казанышы»,- дип яза кинорежиссер Алексей Барыкин

**2** "Безнең аны күрсәтергә хакыбыз бар, бу документаль әсәр түгел, бу нәфис фильм. Нәфис фильмның үз мөмкинлекләре бар. Без дөреслекнең миллионлаган бер өлешен генә күрсәткәнбездер. Дөреслекне чыгарсаң, низагка да ерак түгел. Кемдер адекват кабул итте. Әйтик, татарлар 10% кына яши торган Алабуга шәһәрендә ул сигез мәртәбә барды, заллар шыгрым тулы булды. Кайбер кеше аны фильм итеп карады, кемдер анда сәясәт табарга теләде. Ләкин ул нәфис фильм иде. Башка андый фильм булмаячак», -дип яза Ф. Бәйрәмова.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!